# Ислам нуры

«Диндә көчләү юк, ләкин өндәү һәм өйрәтү бар»
(Коръән Кәрим. 2-256)

12+

№ 6 (706) 26 март 2020 ел (1441, Шәгъбан) Дини-иҗтимагый газета 1995 елдан чыга


*2020 ел - ТАССР төзелүгә 100 ел, Татарстанда Туган тел елы*

## СӨЙЛӘШҮ ӘДӘПЛӘРЕ



Тел — адәм баласының күңелендә булган ачу, мәрхәмәт, йомшаклык, катылык кебек нәрсәләрне ачып бирүче; гыйлем вә әдәп һәм мәгърифәт кебек нәрсәләрне күрсәтүче булган әгъзасыдыр. Шуның өчен телегезне дөреслектән башка нәрсә өчен кузгатмагыз, тәрбиясез сүзләр сөйләмәгез. Кешенең сәламәтлеге телне саклауда икәнлекне онытмагыз! Арттырып сөйләмәгез, әмма һич ялган сөйләмәгез, гайбәт сөйләмәгез, сүз йөртмәгез, белмәгән нәрсәләрне сөйләргә керешмәгез, бер кеше сүз башлагач, тәмамламастан элек, гәрчә ахыры сезгә мәгълүм булса да — калдырып китмәгез! Гомуми мәҗлесләрдә адәм тәнендә булган гаепләр хакында сөйләшмәгез, бер кеше хакында булган сүзне, башкалардан күчереп булса да, хикәят итмәгез сөйләмәгез! Үзегезне вә балаларыгызны гына сөйләп гомер уздырмагыз, иярченнәрегезне мактамагыз, ата-баба, нәсел вә кабилә һәм остазларыгыз белән мактанмагыз, адәм баласы үзе камиллектән мәхрүм булганы соңында, һичбер тарафтан камиллек килмәячәгенә нык ышаныгыз! Һичбер адәмгә ләгънәт итмәгез, каһәрле дога кылмагыз вә һичкемне сүкмәгез, вә һичкемне хурламагыз, яла якмагыз, хаҗәтегезне үтәгән вакытыгызда сөйләшмәгез, мөэмин вә башка кешеләрне куркытмагыз, өченче кеше бар икән, икегез яшерен сүз сөйләмәгез, усал эш артыннан йөрүчеләргә юл өйрәтмәгез, Аллаһы Тәгаләнең бер тел вә ике колак бирүдә, ишеткән нәрсәләрнең фәкать яртысын гына сөйләргә тиеш икәнлегенә ишарә барлыгын белми тормагыз!

**(Риза ФӘХРЕДДИН, “Әхлак гыйлеме”ннән.** *Фото интернеттан алынды.*)

## Чаллы яңалыклары



14 мартта Чаллы шәһәренең “Ак мәчет” мәдрәсәсендә “Җәмгыять тормышын тотрыкландыруда ислам диненең әһәмияте” исемле V Халыкара (Россия, Төркия, Әзербәйҗан, Казахстан, Сирия галимнәре катнашында) фәнни-гамәли конференция булып узды. Бу конференция эшен алып баруда 14 фән докторы, профессорлар, 20 фән кандидаты, магистрлар, фәнни-тикшеренү институтларының фәнни хезмәткәрләре, мәдрәсә җитәкчеләре һәм мөгаллимнәре катнашты. Конференциядә мәгарифкә, җәмгыятьтә барган мөһим проблемаларга кагылышлы мәсьәләләр күтәрелде һәм аларны чишү юллары тикшерелде.

***

Татар мөселман яшьләре өчен башланып киткән “Максат” проектының икенче дәресе булып узды. Кичке намаздан соң 18:00 сәгатьтә башланган әлеге чарада информацион агым, аның зыяны һәм ничек аннан сакланып булганлыгы турында фикер алышынды. Дәрес азагында проектта катнашучыларга өй эше бирелде: смартфонга социаль челтәрләрдә әрәм иткән вакытны чутлау өчен программа кую һәм икенче дәрескә кадәр, бер атна эчендә ул вакытны максималь рәвештә киметү. Instagram, WhatsApp, Youtube һәм Вконтакте приложениеләрен иң аз кулланган катнашучы үзенә өстәмә бер балл алачак. Ай азагында иң күп балл җыйган актив катнашучыга бүләк тапшырылачак. Чара тәмле чәй өстәле артында әңгәмә рәвешендә дәвам итте.

***



13 һәм 14 март көннәрендә “Нур-Ихлас” мәчетендә үткәрелгән азан әйтү курсларында һәм “Ислам. Беренче. адымнар” проектында белем алган шәкертләрнең чыгарылыш мәҗлесе булып үтте. Азан әйтү курсларын 25кә, ә Ислам дине нигезләрен өйрәнү дәресләрен 20гә якын кеше тәмамлады. Аларның барысына да сертификатлар тапшырылды.

“Ислам. Беренче адымнар” проекты беренче тапкыр шәһәребездә 2019 елны, Сидоровка бистәсендә урнашкан “Ихлас” мәчетендә үздырылган иде. Бу елны ул “Нур-Ихлас” мәчетендә шәһәребез имамнары тарафыннан үткәрелгән 5 дәрес эчендә шәкертләрне ислам дине нигезләре белән таныштырды. Үз чиратында азан әйтү курслары мәчет мәзиннәрен һәм теләк белдергән башка ир-атларны матур һәм дөрес итеп азан әйтергә өйрәтүне үз өстенә алды. Икешәр сәгатьлек 4 дәрес дәвамында “Ихлас” мәчете имамнары шәкертләрне азан кагыйдәләренә һәм аны әйтү төрләренә өйрәттеләр.

**Нияз ГАЗИЗОВ.**

## ТР МДН хәбәр итә

Рәҗәб аеның 23 нче көнендә ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең Голәмәләр шурасы утырышы узды. Татарстанның дини оешмаларында коронавирус таралуны булдырмау чараларын күрү – көн тәртибендә төп мәсьәлә шул булды. Коронавирус инфекциясе (COVID-19) таралу куркынычы белән бәйле рәвештә, ислам хокукының төп принципларына таянып, Шура әгъзалары тарафыннан түбәндәге вакытлыча тәкъдимнәр кабул ителде:

Намазга чакыруны (азан) гадәттәгечә үтәргә, намаз башлану турында игъланны (камәт) азаннан соң ук әйтергә, җәмәгать белән намаз укуны бары мәчет хезмәткәрләре (имам, мөәзин, кизү торучы зат) катнашында гына башкарырга; мәхәллә кешеләре өчен мәчетләрдә һәм намаз бүлмәләрендә индивидуаль рәвештә (җәмәгать белән түгел) биш вакыт намаз уку мөмкинлеген оештырырга; җомга намазын башкарганда фарыз гамәлләр белән чикләнү: җомганың мәҗбүри гарәп телле хөтбәсен озакка сузмыйча (3-5 минут) һәм ике рәкәгать намаз укырга; иммунитеты көчсезләнгән, сәламәтлеге какшаудан курыккан дин кардәшләргә массакүләм дини чараларга, шул исәптән җомга намазларына бару киңәш ителми, шул рәвешчә җәмәгать намазларыннан тыелып торуны гөнаһ кылу дип санамаска; мәҗлесләрне, никах һәм исем кушу мәҗлесләрен дә, күп кеше катнашында оештыру гадәтен туктатып торырга; Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте мәчетләрендә, намаз бүлмәләрендә һәм уку йортларында белем бирү һәм тәрбия чараларын уздыруны туктатырга; мөмкин булганча, кул биреп һәм кочаклашып башкарыла торган традицион дини сәламләшүдән тыелып торырга; җеназа намазларын ачык һавада мөмкин кадәр азрак кеше катнашында үткәрергә; ТР мөселманнары Диния нәзарәте структурасына керә торган барлык мәчетләргә, гыйбадәт кылу бүлмәләренә, уку йортларына һәм оешмаларга кабул ителгән тәкъдимнәр буенча хәбәр бирүне оештырырга.

Санап үтелгән әлеге тәкъдимнәрне 2020 елның 15 апреленә кадәр яисә башка карарлар кабул ителгәнчегә кадәр гамәлдә дип санарга.

# Тагын гайбәт турында

***Мөхтәрәм мөселман кардәшләрем, Аллаһы Тәгалә барчабызга да исәнлек-саулык биреп, иманлы тормышыннан аермаса иде. Эшләгән изгелекләребез кабул булып, белеп яки белми кылган гөнаһ-хаталарыбызны ярлыкаса иде. Әгәр бер-беребезне кулыбыз яки телебез белән рәнҗеткән булсак, гафу сорап бәхилләшергә насыйп булсын. Чөнки Пәйгамбәребез (с.г.в.): “Мөселманның кулыннан да, теленнән дә башка мөселманнар зарар күрмәсләр”, - дигән.***

Динебез буенча, мөселманнар дуслык, тынычлык, өлфәт һәм мәхәббәт эчендә яшәргә тиеш. Кешеләр арасында дуслык, туганлык хисләрен бетереп, капма-каршылык, дошманлык китереп чыгара торган җирәнгеч нәрсәләрнең берсе – гайбәттер.

“Бер кеше Аллаһы Тәгаләгә һәм ахирәт көненә иман китерсә (ышанса), күршесенә яхшылык итсен. Бер кеше Аллаһы Тәгаләгә һәм ахирәт көненә иман китерсә, кунагына хөрмәт кылсын. Бер кеше Аллаһы Тәгаләгә һәм ахирәт көненә иман китерсә, сөйләгән вакытында яхшы сүз сөйләсен, юкса тик торсын!” – дип әйткән Мөхәммәд (с.г.в.).

Гайбәттән, сүз йөртүдән, кешеләрне рәнҗетә торган ямьсез вә начар сүзләрдән тыелырга кирәк. Чөнки болар барысы да ислам динендә хәрамдыр. Аллаһы Тәгалә “Һүмәзә” сүрәсенең 1 нче аятендә: “Үкенеч вә һәлакәтлектер, һәр сүз йөртүчегә вә гайбәт итүчегә, кешене түбәнсетеп аның абруен бетерергә тырышучыларга.” Хәдистә: “Сүз йөртүче кеше җәннәткә кермәс”, диелә.

Кызганыч ки, бүгенге көндә гайбәт сөйләү, сүз йөртү киң таралган. Аннан башка бернинди мәҗлес тә үтми, хәтта Коръән мәҗлесләрендә дә үзебез дә сизмәстән гайбәткә кереп китәбез. Гайбәт сөйләмик, гөнаһка кермик дисәң, “Бу гайбәт түгел – гыйбрәт, без бит ялган сөйләмибез, дөресен сөйлибез”, - дип аклана башлыйлар.

Дөрестән дә, гайбәт нәрсә соң ул? Бу сорауга тулы җавапны Пәйгамбәребез Мөхәммәд (с.г.в.)нең хәдисеннән (әйткән сүзеннән) таба алабыз. Әбү Һөрайрә разыйАллаһу ганһедән риваять ителә. Пәйгамбәребез (с.г.в.) әйтте: “Гайбәтне беләсезме?” Сәхабәләр әйттеләр: “Аллаһы һәм Аның Рәсүле белүчерәктер”. Пәйгамбәребез (с.г.в.) әйтте: “Әгәр кардәшеңне ул сөйми торган нәрсәсе белән искә алсаң, хаклыкта, син аны гайбәт кылдың”, – диде. “Кардәшемдә мин әйткән нәрсә булса да гайбәт күрәсеңме?” – дип сорагач, Пәйгамбәребез (с.г.в.) әйтте: “Әгәр ул кардәшеңдә син әйткән нәрсә булса, һичшиксез, син аны гайбәт кылдың. Әгәр ул кардәшеңдә син әйткән нәрсә булмаса, хаклыкта, син аны бөһтан кылдың, ягъни аңа яла яктың”. Фәлән кешенең киеме кыска, йә булмаса фәлән кешенең киеме озын, нишләп кыскартмый икән дип әйтү дә гайбәттән санала. Чөнки син аның нәфесе турында искә аласың, шуңа күрә бу әйтүең гайбәттән китә.

Хәбәр итүләре буенча, бер кыска буйлы хатын Пәйгамбәребез (с.г.в.) янына йомыш белән килгән иде, ул хатын киткәч, Гайшә анабыз (аннан Аллаһ разый булсын): “Ул хатынның буе нишләп кыска?” – дип сораган. Пәйгамбәребез (с.г.в.): “Син аны гайбәт кылдың”, – ди. Гайшә анабыз: “Ул хатында булмаган нәрсәне әйтмәдем”, – дигәч, Пәйгамбәребез (с.г.в.): “Аңарда булган нәрсәләрдән начаррагын әйттең”, – дип җавап биргән.

Гадәттә, мөселман кеше башкалар өстеннән гайбәт сөйләми.

Хәдистән аңлашылганча, берәр кешенең үзенә ошамаган сыйфатларын, хәрәкәтләрен, сүзләрен сөйләсәк, гайбәтчеләрдән булабыз, әгәр үзебездән арттырып ялганлап сөйлибез икән, тагын да зур гөнаһка – бөһтанчылыкка батабыз. Аллаһ каршында бу гөнаһыбыз гафу ителсен өчен алдан гайбәтен сөйләгән кешедән бәхиллек сорарга кирәк, һәм кемнәр алдында бу гайбәтне сөйләдек, аларга да ялгышуыбызны әйтү, теге кешенең күркәм, яхшы сыйфатларын хәбәр итү кирәк була. Гайбәт сөйләгән очракта, изгелекләребез гайбәте сөйләнүчегә китә, ә гайбәтчегә теге кешенең гөнаһлары языла.

Кешенең гайбәт сөйләп йөрүе аның җирәнгеч начар чир белән авырганына дәлил булып тора. Шуңа күрә дә, кеше үзенең башкалар өстеннән гайбәт сөйләп йөрү гадәтен Коръән Кәрим аятьләре һәм хәдисләр белән дәваларга тиеш.

Аллаһы Тәгалә “Хуҗүрат” (Бүлмәләр) сүрәсенең 12 нчы аятендә: “Әй мөэминнәр! Уйларның күбесеннән сакланыгыз. Хакыйкатьтә, уйларның күбесе гөнаһтыр. Һәм кешеләрнең гаепләрен тикшермәгез, кеше гаебен эзләмәгез, шымчылык кылмагыз һәм берләрегез башкалар хакында гайбәт сөйләмәсен! Әллә сезнең берәрегез үлгән кардәшенең итен ашауны сөярме? Сез бит аннан җирәнәчәксез, гайбәт сөйләүдән дә җирәнегез, шулай ук мәкърүһ күрегез! Аллаһудан куркыгыз, гайбәт эшләреннән тәүбә итегез! Дөреслектә Аллаһ тәүбә итеп төзәлгән кешеләрне гафу итүче һәм рәхимле”, – ди.

Ягъни адәм баласы барча уйларын сөйләп йөрүдән тыелса, күп кенә гөнаһлардан үзен дә һәм дус-ишләрен дә явызлык эшләүдән тыйган булып чыга. Шайтан мәлъгун кешегә берсеннән-берсе бозык уй- фикерләр кертеп, бу иң зирәк фикер дип, кешедән әйттерергә тырыша. Юкка гына әйтмиләр: “Кисәргә ниятләгән нәрсәңне җиде кат үлчә, аннан соң гына кис”, – дип. Ошбу әйтем беренче чиратта кешенең башына килгән уй-фикерләренә кагыла. Уй ике төрле була. Берсендә гөнаһ бар. Икенчесендә гөнаһ юк. Гөнаһ булган уй – сөйләнә торган уй. Ә гөнаһ булмаган уй – күңелдә кала торганы. Шуңа күрә дә үзеңнең фикереңне әйткәнче уйларга кирәк: гайбәт түгелме, үзара дошманлык тудырып фетнәгә алып бармыйммы... Ә гайбәт сөйләү кардәшеңнең үләксәсен ашау белән бер ди Аллаһы Тәгалә.

Пәйгамбәребез (с.г.в.) гайбәт сөйләүчеләрне яратмаган. Әгәр бер кеше аның янында гайбәт сөйләргә тотынса, гайбәтнең хәрам, гөнаһ булуын хәтерләтә торган булган. Бер хәдистә ул болай дигән: “Гайбәт сөйләүче белән гайбәтне тыңлаучының гөнаһлары уртактыр”.

Мөселман булган кеше, башкаларның гаебен эзләп, ул турыда анда-монда сөйләп йөрмәс. Аллаһыга ныклап ышанган кеше мөселман кардәшенең хата һәм гаепләрен сер итеп сакларга тырышыр. Чөнки Пәйгамбәребез (с.г.в.) болай дигән: “Кем дә кем бер мөселман кардәшенә ярдәм итсә, Аллаһ та ул кешегә ярдәм итәр. Кем дә кем бер мөселман кардәшенең кайгысын бетерсә, Аллаһ та Кыямәт көнендә аның кайгыларының берсен бетерер. Кем дә кем бер мөселман кардәшенең гаебен белдермәсә, Аллаһ та ахирәттә аның гаебен белгертмәс”.

Әмма берәү җәмгыятькә, мөселманнар арасында дуслыкны, татулыкны боза торган зарарлы эш кылып йөри торган булса, мондый кеше турында җәмгыятькә зыян китерүче икәнен мөселманнарга сөйләү гайбәттән саналмый. Чөнки Пәйгамбәребез (с.г.в.) әйткән: “Аның яманлыгыннан кешеләр саклансын өчен, бозыклык иясенең бозыклыгы хакында сөйләгез”, “Әгәр берәү оятсызлык чикмәнен өстеннән салса, аны сөйләү гайбәт булмас”, – дигән.

Пәйгамбәребез (с.г.в.): “Явызларыгыз хакында сезгә хәбәр биримме?” – дигәч, сәхабәләр: “Әйе, әй Аллаһының Рәсүле”, – дип җавап бирделәр. Пәйгамбәребез (с.г.в.): “Алар – әләкчелек белән йөрүчеләр, бер-берсен яратучыларның арасын бозучылар һәм начарлыктан пакъ булган кешеләрне гайбәт белән пычратырга тырышучылар”. Ягъни явыз кешеләр – мин дөреслек яклы, дөреслекне яратам дип, бер кардәше өстеннән башка кардәшенә әләкләп, үзара татулыкка тыштан гына шатланган булып, күңеленнән бер-берсе белән дустанә булган кешеләрнең дуслыгына дошман булып, гайбәт белән араларын бозарга тырышучылар икән.

Кеше, башкаларның гаепләрен тикшергәнче, иң беренче чиратта үзендә булган кимчелекләрне бетерергә, үзен яхшы кеше итеп тәрбияләргә тырышсын. Пәйгамбәребез (с.г.в.) әйткәнчә: “Яхшы мөселман, үзенең гаепләрен тикшергәнлектән, башкаларның гаепләрен тикшерергә вакыт тапмас”.

Икенче бер хәдистә: “Сөенеч булсын шул кешегә: үз гаебен күреп, шуны төзәтү белән шөгыльләнү сәбәпле башкаларның гаепләрен күрергә вакыты булмас, малының артканын тиешле урыннарга сарыф кылыр, ә сүзенең артыгын үзендә калдырыр һәм үзе сөннәт белән гамәл кылыр, аннан үтеп бидгать эшләр кылмас”, – диелә. Ибне Габбас әйткән: “Әгәр дә синең кардәшеңнең кимчелекләре турында сөйлисең килсә, үзеңнең кимчелегеңне исеңә төшер”, – дип.

Әлбәттә, кеше үзенең гаепләрен төзәтү өстендә даими эшләсен өчен, үз гаепләрен күрә белү кирәк. Үз гаепләрен күрә һәм таный белмәгән кешенең генә бөтен эше кеше гаебен тикшерү була. Кайсыбер кешеләр, минем бернинди гөнаһым һәм кимчелегем дә, гаебем дә юк, ди. Ә Аллаһы Тәгалә әйтә: “Мин кешене кимчелекле, гөнаһ кыла торган итеп яралттым”, – ди. Шулай булгач, без Аллаһы Тәгаләдән гаепләребезне күрә торган күз, калеб бирүен сорарга тиешбез. Үз гаебен үзе күрә торган кеше генә бәхетле була. Чөнки Раббыбыз Аллаһ әйткән: “Гөнаһларын-гаепләрен танып тәүбәгә килүчеләрнең кимчелекләрен кичерермен”, – дип. Минем бернинди дә гөнаһым юк дип, Аллаһы Тәгаләгә ышанмаган кеше генә әйтә ала. Ә Аллаһны үзенең Раббысы дип таныган кеше Аның сүзенә ышана.

Мөэмин-мөселманның дуслары булган кебек, дошманнары да юк түгел. Әгәр дә без гаепләребезне дошманнар авызыннан ишетәбез икән, бу гаепне кичекмәстән төзәтү өстендә эшли башларга тиеш булабыз. Башкаларның, бигрәк тә җитәкчеләрнең, кимчелеген сөйләп йөрергә яратучыларга бүләкләребезне бирергә онытмыйк, чөнки алар гаебе сөйләнүче кешенең гөнаһларын үзләре теләп алучылар.

Бер галим: “Бу кадәр әдәпне кемнән өйрәндең?” – дип сорагач, “Әдәпсезләрнең әдәпсезлекләрен күрдем дә, шулардан сакландым”, – дип җавап биргән. Ягъни бозыклыктан сакланып әдәпле булган.

Бүгенге көндә күпчелек кешеләрнең яшәү мәгънәсе ашау өчен, дөньяда яшәү һәм дөньяда яшәү өчен ашаудан гыйбәрәт. Бу рәвешчә яшәүчеләр гайбәт, сүз йөртү, әләк, яла ягу һәм дингә төрле мәгънәсез яңалыклар кертү кебек нәрсәләр белән вакыт уздырмасалар, дөньяда гомерләрен ничек уздырырга кирәк икәнлеген күз алдына да китерә алмыйлар. Ә эш белән мәшгуль кешеләр гомерләрен гайбәт сөйләп үткәрү түгел, кирәкле сүзләрен кешеләргә җиткерергә вакыт таба алмыйлар. Сөекле Пәйгамбәребез (с.г.в.) әйткән: “Әй телләре белән иман китереп тә, иманнары күңелләренә кермәгән җәмәгать! Мөселманнарның гайбәтләрен сөйләмәгез, аларның кимчелекләрендә казынып, чокчынып тормагыз, кем дә кем мөселманнарның кимчелекләрен тикшерсә, Аллаһы Тәгалә дә аның үз кимчелекләрен тикшерер. Аллаһы Тәгалә кемнең гаебен тикшерсә, аны үз өендә мәсхәрә кылыр”. Ягъни гайбәт сөйләү – теле белән иман китереп, күңеле белән иман китермәүче монафыйклар эше, дип безләргә әйтә. Пәйгамбәребез (с.г.в.) саубуллашу хаҗында Гарафәттә бөтен мөселманнар алдында: “Дөреслектә, каннарыгыз, малларыгыз һәм абруйларыгыз бер-берегезгә хәрам”, – дип нәсыйхәт әйткән. Ягъни мөселманны үтерергә һәм малына, байлыгына кагылырга ярамаган кебек, мөселманның абруен төшерә торган гамәл кылу – сүз сөйләү дә тыелган эш булып тора.

Халык каршында дини саналу өчен һәм динне саклаучы булып күренү өчен, мөселманнарны кяфер дип атау – үзе азгынлык һәм тыйнаксызлык билгесе булып тора.

Гайбәтнең дөньяви тормышыбызда һәркем өчен зыяны күп булган кебек, ахирәт өчен дә зарары зур. Гайбәт изгелекләр һәм гыйбадәтләрдән казанган савапларның югалуына сәбәп була. Шуңа күрә сөекле Пәйгамбәребез (с.г.в.) буш сүз, гайбәт сөйләүнең начар гамәл, Аллаһының рәхмәтенә ирешүдән ерагайта торган эш булуын бик күп хәдисләрендә искә алган.

Вәгазьдә китерелгән аятьләрнең һәм хәдисләрнең мәгънәләрен төптән аңлаган кеше буш сүзләр, гайбәт, ялган сөйләүләрдән сакланыр. Чөнки Кыямәт көнендә Аллаһы Тәгалә каршында һәрбер әйткән сүзебез өчен җавап бирәсебез бар. Кайберәүләр кеше кимчелекләрен барлап тел “чайкауны” берәр ялганны, шаяртып кына әйттем, дип, җиңелгә саный, Аллаһның фәрештәләре бит шаяртып әйттеңме, шаяртмыйчамы – барысын да теркәп куялар.

Аллаһы Тәгаләнең безгә биргән тел нигъмәтен дөрес итеп кулланырга насыйп булса иде. Күбрәк файдалы сүзләр сөйләп, Коръән укып, кешеләрне хикмәт белән туры юлга өндәп, хәрам булган эшләрдән тыярга насыйп булсын. Аллаһы Сүбхәнә вә Тәгалә барчабызга да тәүфыйк-һидәят насыйп әйләсен, бәрәкәтле маллар, бәрәкәтле балалар, үзебезнең телебезгә хуҗа булырга насыйп булсын. Әмин!

**“Туфан” мәчете имам-хатыйбы Равил хәзрәт НУРУЛЛИН әзерләде.**

## БЕЛӘСЕЗМЕ?

***Шөкер сәҗдәсе***

Төрле бәла-казалардан котылганнан соң, яки кеше тормышында берәр шатлыклы вакыйга булса, ул кеше шөкер сәҗдәсен кылырга мөмкин. Аллаһы Тәгаләгә рәхмәтеңне белдергән мондый сәҗдә тиләвәт сәҗдәсе кебек башкарыла. Пәйгамбәребез (с.г.в.) яхшы хәбәрләр алган чагында шөкер сәҗдәсе кыла торган булган. Шөкер сәҗдәсе - мөстәхәб, әмма аны намаздан соң ук башкару мәкрүһ була, чөнки белеме җитеп бетмәгән кешеләр бу сәҗдәне намазның бер өлеше дип уйларга мөмкин. Әлеге сәҗдәне мәкрүһ вакытлардан тыш теләсә кайсы вакытта кылырга була.

**(“Ислам дине нигезләре”ннән).**

## ӘДӘБИ СҮЗ

*Рәзинә МӨХИЯР*

### Буш сүз сөйләмә!

Кирәксез буш сүзләр сөйләп,
Вакыт әрәм булмасын!
Безнең гамәл дәфтәребез
Юк-бар белән тулмасын!

Зекерләрне ешрак әйтик,
Фәрештәләр куансын!
Гамәл-дәфтәр уңнан килеп,
Безнең күңел юансын!

“Кыямәт көне ерак”, – дип,
Шайтан һич алдатмасын!
Ахырзаман билгеләрен
Күрүче адашмасын!

**«Ислам нурына» — 25 ел**

## Актив хәбәрчебез



Рафис хәзрәт Шәйхәйдаров белән “Ислам нуры” газетасында эшләгәндә шактый аралашырга туры килде. Ул безнең штаттан тыш хәбәрчебез булды дисәм дә ялгышмам. Рафис хәзрәт һәр килүемә нинди дә булса яңалык әзерләгән булып чыга иде: йә ул әле генә Оренбург яки Уфа архивында эшләп кайткан, йә яңа бер тарихи китабын нәшер иткән, йә Иранда кыска курсларда булган, йә Санкт-Петербургта узган Фәезханов укуларында катнашкан. Рафис хәзрәт шулай ук Уфадагы ике мөфти белән дә актив хезмәттәшлек итә, алар уздырган чараларда да актив катнашып бара иде. Ягъни ул минем өчен һәрвакыт бай мәгълүматлы кеше булды. Шуны да аерып әйтим: Рафис хәзрәт аша газетабыз укучылары Батырша хәзрәтләре турында күп яңа мәгълүматлар алдылар. Аның үзе катнашкан һәр мөһим чараны фоторәсемнәре белән бергә аерым альбомга теркәп баруын да игътибарга алырга кирәк. Рафис хәзрәтнең һәр эшендә район администрациясе ярдәменә таянуы, алар белән аңлашып, фикерләшеп яшәве дә миңа яхшы таныш иде. Берчакны Рафис хәзрәткә Чаллыда яңа гына нәшер иткән “Чаллы мәчетләре” китабын бүләк иттем. Һәм ул озакламый Балтач районы мәчетләре китабын әзерләде һәм аны бик затлы итеп бастырып та чыгарды. Шунсы бик кызыклы булды: китап әле басылып чыкмаганда ук инде автор тарафыннан аның ярты тиражы сатылган иде.

Рафис хәзрәтнең ахун, имам-мөхтәсиб, имам-хатыйб вазыйфаларын башкаруы, Батырша хәзрәтләре музеен җитәкләве, аңа бәйле чараларны оештыруда катнашуы, район, авыллар тарихын өйрәнүе һәм аларның нәтиҗәсе итеп хезмәтләрен бастырып чыгаруы һ.б. эшләре хакында мин хәбәрдар. Һәм шуңа күрә кайвакытта уйлана идем: “Аны шундый тынгысыз эшчәнлеккә, эзләнүгә нәрсә этәрә? Балачагыннан килгән динилекме? Милләтен яратумы, миллилегеме?” Динебезне өйрәнүдә аның беренче остазы - әбисе булган. Совет чорында Рафис хәзрәт хәрби хезмәткә чакырылгач та дини булуын яшермәгән. Шуңа күрә аның белән атеизм рухында дин нигезләрен аңлатып әңгәмәләр үткәрә торган булалар. Һәм нәтиҗәдә Рафис хәзрәтнең Аллаһы Тәгаләгә ышануын тагын да көчәйтәләр. Чаллыда бер хәзрәтне беләм: ул Исламга атеистик китаплар укып, шулар тәэсирендә килүе турында әйтә иде.

Рафис хәзрәтнең тормыштагы ошбу актив позициясе ул инде заман шаукымы белән генә кузгалмагандыр дип уйлыйм. Чөнки аның нәсел җепләре шул ук дини каһарманыбыз Батырша хәзрәтләренә барып тоташа. Биредә генетик бәйләнеш тә булырга тиеш. Чөнки тормышта бернәрсә дә очраклы гына була алмый. Әлбәттә, Рафис хәзрәтнең киң эшчәнлеген милләттәшләребез күрәләр, бәялиләр, үзен хөрмәт итәләр. 2017 елны Казанда татар имамнары форумында Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов аңа милли мәдәниятебезне һәм рухи-әхлакый традицияләрне үстерүгә, тынычлыкны һәм конфессияара татулыкны ныгытуга зур өлеш керткәне өчен “Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре” дигән мактаулы исем бирелүе хакындагы Указга кул куюын хәбәр итте һәм аңа Истәлек билгесе тапшырды.

Әлбәттә, Рафис хәзрәтне борчыган сораулар да бар. Батырша хәзрәтләренең исемен мәңгеләштерү буенча аның башлангычын әле бар урыннарда да хуплап каршы алалар дип әйтеп булмый. Мәсәлән, 2018 елны Пермь краенда Батырша хәзрәтләре имамлык иткән һәм мәчет каршындагы мәдрәсәдә дәресләр биргән Байавыл (Барда районы) мәчете стенасына истәлек билгесе куелды. Ул авыл өчен истәлекле бер вакыйга булды. Чөнки бу көнне авыл мәдәният сараенда Батыршага багышланган конференция дә узды. Анда төп чыгышларның берсен Рафис хәзрәт ясады. Әмма Татарстанның Батырша эзләре калган Тайсуган, Оренбургның Каргалы авылларында бу эш әле эшләнмәгән. Югыйсә, Әлмәт районы имам-мөхтәсибе адресына үтенеч хаты да юллаган идек. Әмма әлегә җавап юк. Мин Рафис хәзрәткә, аның энергиясенә, активлыгына, динебезне, милли рухыбызны көчәйтү буенча башкарган эшләренә сокланам. Һәм киләчәк аның ошбу чорда башкарган хезмәтләрен тагын да югарырак бәяләр дип ышанам. Әйе, милләтебез киләчәге аның шундый лаеклы уллары кулында.

**Хәлил ШӘРИФ.**
**Рәсемдә: Рафис хәзрәт Шәйхәйдаров.**

## Кылган хаҗым – Аллаһ биргән таҗым

*(Дәвамы. Башы газетаның алдагы саннарында)*

Самолетыбыз Мәдинә аэропортына исән-имин төшеп утырды. Ходаем, мин ата-бабаларымның төшенә дә кермәгән изге Мәдинә җирендә!.. Мәдинә аэропортындагы көтү залында конденционерлар су бөркеп торалар. Чатыр астыннан чыксаң, кыздыра, ә эчтә салкынча. Күпне күргән, күп йөргән апа-әбиләр, сумкаларыннан мамык шәлләрен алып, аркаларына салдылар һәм авыз эченнән генә белгәннәрен укып, утыргычларга барып утырдылар. Шунда ук ирләр һәм хатын-кызлар өчен тәһарәт, намаз бүлмәләре. Кунакханәгә алып китү өчен автобус килеп туктады. Безнең багажларны махсус төяүчеләр аерым автобуска урнаштырдылар. Без утырган автобус эчендәге табло 48 градус эсселекне күрсәтә иде. Урамда өтеп ала торган кайнар һава.

Артык мәшәкатьләрсез генә кунакханәгә барып урнаштык. Җитәкчеләребез Мәдинә шәһәрендә ике көн ярым булачагыбызны хәбәр иттеләр. Номерларга урнашып, бер-ике сәгать ял иткәч, пәйгамбәребез (с.г.в.) мәчетенә киттек. Пәйгамбәребез (с.г.в) йөргән урамнар буйлап аның мәчетенә барабыз. Мәчетнең зурлыгы турында әйтеп бетерә торган түгел. Әйләнә-тирәсе бөтенләе белән ак мәрмәрдән түшәлгән. Кояш кызуыннан саклап тору өчен махсус чатырлар эшләнгән. Алар кояш чыкканда әкрен генә ачылалар да көн сүрелгәндә ябылып бетәләр.

Менә без пәйгамбәребез мәчетендә. Ап-ак колонналы, ак мәрмәр идәнгә чия-кызыл келәм җәелгән биниһая олы ап-ак мәчет. Һәр колонна янәшәсендәге шүрлектә төрледән-төрле зурлыктагы изге Коръәннәр куелган. Намаз вакыты җиткәнче, без ике рәкагать мәчет намазы укыдык. Әле вакыт бар иде. Аякларны бөкләп утырган килеш, мин пәйгамбәребезнең (с.г.в) мәчетен күзәтә башладым. Тукта... кайдадыр мин бу җирне күргән идем бит... Кайда күрдем соң? Бик тә таныш җиргә охшаган! Исемә төште, һәм мин эсселе-суыклы булып киттем. Мин бит моны нәкъ 25 ел элек төштә күргән идем. Ап-ак колонналы, очы-кырые күренмәгән ап-ак мәчет, бар да ап-ак киемле халык белән тулган. Мин аяк бөкләп утырам имеш... Каршымда зур гына Коръән. Кем әйтер могҗиза юктыр дип... Аллаһының кодрәте чиксез шул!

(Дәвамы бар).

**Рәфкать ШАҺИЕВ,**
**Әлмәт шәһәре.**

## Дөрес яшибезме?..

Коръәни Кәримдә “Шура” сурәсендә Аллаһ Тәгалә: “Мин ризыгымны бер киңәйтәм, бер тарайтам. Әгәр мин ризыгымны тигез генә бирсәм, Адәм баласы минем турыда онытa, бозыклык кыла башлый”, дип әйткән. Димәк, кризис җибәреп, Аллаһ Тәгалә Адәм баласының ризыгын кыса. Бу исә безнең яшәвебездә нәрсәдер дөрес түгел дигәнне аңлата. Аллаһ Тәгалә Коръәндә: “Вакытында укылган намаз укучысын бөтен бозыктан саклый, һәм ул – зекернең иң бөеге”, дип бирәбезме? Менә без 1990 елның апрель аенда Дагыстанга бардык. Ураза вакыты. Мин ул вакытта колхоз икътисадчысы идем, янымда авыл хуҗалыгы идарәсеннән бер кеше, ике колхоз рәисе иде. Гөрләп чәчү бара, ә совхоз ашханәсе эшләми. Нигә болай дип сорагач, “Бездә 90 процент кеше ураза тота, тотмаганы да кешегә күрсәтеп ашамый”, диделәр. Өйлә вакытында басу буйлап үтеп барабыз: тракторист егет машинасын сүндергән дә, намазлык җәеп намазга

әйтә. К[illegible]шләүче беренч[illegible]н сөяп бүген б[illegible] намаз укыйлар. Шаккаттык! Сорагач, “Бездә тел ачылгач та әти-әниләребез таләп иткән әйбер – ул намаз. Алар янында укымыйча берничек мөмкин түгел”, диделәр. Инде дингә ирек бирелгәнгә 30 еллап була, ә без үз балаларыбыз, оныкларыбызга шул Дагыстан балаларына куйган таләпләрне куябызмы?..

**Җәлил хәзрәт ФАЗЛЫЕВ,**
**Татарстанның баш казые.**

## Яулык бәйлим дисәң...



Соңгы вакытта тыйнак киемнәр киеп, яулык бәйләп йөрүче хатын-кызларыбыз артканнан-арта. Хәзер дин кануннары белән киенергә теләгән хатын-кызларыбызга кием эзләп яки тектереп интегәсе юк – махсус кибетләр ачылып кына тора. Күптән түгел Чаллы шәһәрендә җырчы Гүзәлемнең яулыклар кибете үзенең ишекләрен ачты. «Торговый квартал» сәүдә үзәгенең ул бүлегендә кибет хуҗалары Гүзәлем белән Салават Миңнехановлар килгәндә монда алма төшәр урын да калмаган иде. Сәүдә ноктасын ачу тантанасы бик күркәм булды – иң башлап сүз Габдрәшид хәзрәткә бирелеп, кибетнең эше Коръән сүрәләреннән, дога кылудан башланды. Ишеккә тарттырылган кызыл тасманы кисү дә хәзрәткә йөкләтелде. Эчкә үтәргә теләүчеләр бик күп булып, кибет барысын берьюлы сыйдыра алмады, әмма беркемнең аңа карап кәефе төшмәде, чөнки бер читтә вакытны үткәрергә менә дигән чара – Гүзәлемнән яулык бәйләү буенча мастер-класс башланды. Кибет хуҗабикәсе, үзләрен уратып алган гүзәл затларыбызга һәр хәрәкәтен аңлатып, катнашырга теләк белдергән биш ханымга матур итеп яулык бәйләде. Әйтергә кирәк, кулланган яулык, палантин, башлык, чәч җыйгычлар – берсе дә кире сүтелмәде, барысы бүләккә калды. Яулык сатып алган хатын-кызларга шулай ук аны Гүзәлемнән бәйләтеп китү мөмкинлеге бирелде, күпләр бу мөмкинлектән файдаланып калырга ашыкты. Бәйрәмнең азагында исә сатып алучылар арасында лотерея уйнатылды. Приз итеп шулай ук яулыклар һәм палантиннар бирелде. Килгән балалар да бүләксез калмады – аларга кабартылган шарлар таратылды.

Кайчан гына шәһәр уртасында, зур сәүдә үзәкләрендә, хәзрәт чакырып, мондый чаралар үткәрү турында без әле хыяллана да алмый идек. Бүгенге көндә җәмгыятебездә Ислам диненә карашның уңай булуы, халкыбызның аңа тартылуы, хатын-кызларның, бигрәк тә яшьләрнең тыйнак киенергә омтылуы бик сөендерә, киләчәккә өмет уята.

**Гүзәл МӘРДӘНОВА,**
**Чаллы.**

## «ИКЕ» саны белән бәйле хикмәтләр

Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәләм әйтте: “Аллаһка ышану һәм мөселманнарга файдалы булу дигән ике сыйфаттан кыйммәтрәк һәм кадерлерәк нәрсә юктыр. Ә Аллаһка ширек кылу, ягъни Аның тиңдәше бар дип әйтү һәм мөселманнарга зарар китерү кебек ике сыйфат – иң начар нәрсәдер...”

Әбү Бәкер (радыйәллаһү гәнһү) әйтте: “Алдан хәстәрләп куелган игелекле гамәлләрдән башка каберенә кергән кеше диңгездә көймәсез йөзеп барырга җыенган бер бичара кебектер...”

Гомәр ибне Хәттаб әйтте: “Бу дөньяның хөрмәте белән шөһрәте байлыкта булса, ахирәтнең хөрмәте белән шөһрәте изге гамәлләрдәдер”.

Госман ибне Гаффан әйтте: “Бу дөньяны кайгырту йөрәкне караңгылата, ә ахирәтне кайгырту аны яктырта”.

Көлә-көлә гөнаһ кылучы кешене Аллаһы Тәгалә җәһәннәмгә кертер һәм шул кеше ачынып елар... Ә елый-елый булса да Аллаһка итагать итүчене Аллаһы Тәгалә җәннәткә кертер һәм ул бәндә көләр һәм бик сөенер.

“Аллаһтан яхшырак дустым бар” дип хисаплаган кеше Аллаһы Тәгалә турында бик аз белә. “Нәфестән дә яманрак дошманым бар” дип уйлаган кеше үзен бик аз белә.

Дөрестән дә, шәһвәт патшаларны колга әйләндерә ала, ә сабырлык колларны патша дәрәҗәсенә җиткерергә мөмкин... (Йосыф һәм Зөләйха кыйссасын искә төшерегез...)

Үз акылы идарә иткән, шәһвәте әсирлектә булган кеше – Бәхетле! Шәһвәте идарә иткән һәм акылы “әсир” булган кеше исә – бәхетсез...

Хәрамны калдырып, хәләл ризыкны ашаган кешенең уй-фикерләре чиста, ниятләре изге булыр.

Хәрәкәтләнү тәннең исәнлеген күрсәтүче билге булган кебек, гыйбадәт кылу Аллаһны тануның билгесе булып тора.

**Ришат хәзрәт КУРАМШИН әзерләде.**

## Телсез калма!

*Балалар өчен*




*Сабыем, дип туган телдә*
*Әниең сине сөйгән.*
*“Бәхетле бул,*
*балам”, - диеп,*
*Әтиең күккә чөйгән.*
*Туган телең - татар теле,*
*Синең телең инде ул.*
*Тәпи киткән,*
*үсеп җиткән -*
*Синең җирең инде ул.*
*Туган телне сайламыйлар,*
*Туган тел - ул бер генә.*
*Бабаңнар сөйләшкән телне*
*Син дә өйрән, бел менә.*
*Татар теле - синең тел ул,*
*Ягымлы ул, җылы ул.*
*Син көлгәндә ул да көлә,*
*Син еласаң, елый ул.*
*Әзрәк елап, күбрәк көлеп*
*Син дә үсәрсең әле.*
*Тик онытма туган телең,*
*Телсез калма син, яме?*

**Лилия Гыйбадуллина**

*Саулыгым – байлыгым*

## СУГАН



Суган сәламәтлек өчен бик файдалы. Аеруча кызыл суган дәвалау үзлекләренә ия. Аның составындагы дисульфидлар бактерияләрне үтерүгә сәләтле, кандагы шикәр белән холестеринны киметә, организмны яман шештән саклый; аллицин дигән матдә исә тромблар барлыкка килүне кисәтә, кан тамырлары тышчасының сыгылмалылыгын тәэмин итә. Суган организмга инфекцияләргә каршы көрәшергә ярдәм итә. Ул С һәм В витаминнарына бай. Алар исә матдәләр алмашына һәм нерв системасы эшчәнлегенә уңай тәэсир итә. Атеросклерозны кисәтү максатыннан, суган белән бал катнашмасын ашагыз. Гөмбәчек авыруыннан котылу өчен зыян күргән урынга угычта уылган суган белән бал катнашмасын сылагыз. Аш серкәсендә пешкән суганны исә сөялле урынга куеп торыгыз. Суган чәчне ныгыту чарасы да булып тора. Кавыктан котылырга теләсәгез, аның кабыгыннан «шулпа» ясап, башыгызны шуның белән юыгыз. Җыерчыклардан котыласыгыз килсә, суган белән балдан ясалган катнашманы биткә сөртергә мөмкин.

**Нәшире**
**Иршат Гыйльметдин улы ШӘЙХАТТАР**

**Баш мөхәррир**
**Муллагалиева А. Г.**
**Тел.:** (8552) 70-51-09
**Факс:** (8552) 70-51-45

* * *

**Оештыручылары:**
Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан җөмһүрияте мөселманнары Диния нәзарәте, “Ислам нуры” дини эшмәкәрлек Үзәге

Газета мәкаләләрен күчереп басканда аларның “Ислам нуры”ннан алынганын күрсәтү мәҗбүри.

Редакциягә килгән хатларда авторларның стиле саклана.

**Хатларны 423802, Чаллы Үзәк ур., 72 адресы буенча юллау кирәк.**

**Электрон хатлар өчен:**
islamgazeta@mail.ru

Мөселманнар арасын бозуга, үзара каршылыкларга китерергә мөмкин булган хатлар, шикаятьләр газетада басылмый.

Дин-шәригать мәсьәләләренә кагылышлы язмалар, укучы сораулары Татарстан Диния нәзарәтенең баш казые, Чаллы төбәге мөхтәсибәтенең гыйльми Советы тарафыннан өйрәнелә һәм аларга җавап бирелә.

Россия Федерациясе матбугат, телерадиотапшырулар һәм массакүләм коммуникацияләр Министрлыгының Идел буе төбәкара территориаль идарәсендә ПИ № 7-0997 саны белән 2001 елның 15 ноябрендә теркәлде.

“Роспечать” агентлыгы каталогына кертелгән, язылу ел әйләнәсендә Россия Федерациясе буенча алып барыла.

Айга ике мәртәбә чыга.

**Тиражы: 1500**
**Индексы 54149**

* * *

Хөрмәтле укучыбыз!
Газетабызны укып чыккач, аны туганнарыгызга, танышларыгызга, тапшырсагыз иде. “Ислам нуры”ның һәр саны кулдан-кулга күчеп динебезне таратырга ярдәм итсә иде. Әмин.

Шулай ук укучыларыбыз, Коръән аятьләре язылу сәбәпле, газетаны кирәкмәгән урыннарга ташлаудан сакланырлар дип ышанабыз.

* * *

Газета компьютерда җыелды, офсет ысулы белән “Ислам нуры” басмаханәсендә басылды.

**Нәшир, типография һәм редакция адресы:**
**423802, Яр Чаллы, Үзәк урамы, 72**

**Басарга кул куелды: график буенча 26 март 16 сәг. фактта 26 март 16 сәг.**

**Бәясе ирекле**